**Березняк авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**2022 елның 7 июне** **№ 12**

Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 21 ноябрендәге 1 номерлы Березняк авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Уставының 20 ст. нигезендә Березняк авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 21 июнендә 18 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 21 ноябрендәге 1 номерлы Березняк авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 21 ноябрендәге 1 номерлы Березняк авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзацларны өстәргә:

«-янгын гидрантларын, су алу колонкаларын һәм аларны комплектлау җайланмаларын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү;»

«- Березняк авылы зиратын киймалау, капка урнаштыру, склад түбәсен алыштыру, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен урын ясау һәм контейнерлар урнаштыру (материал сатып алу, килешү буенча түләү)- проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Березняк авыл
җирлеге башлыгы Р. Ф. Шәрипов

ОГРН 1021607753276
ИНН 1623001847